**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 19 июнь № 393

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Гаризага түбәндәгеләр теркәлә ала:

а) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

б) муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының объектларны урнаштыруга ризалыгы – объектны урнаштыру Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрендә гамәлгә ашырылган очракта;

в) объектларны урнаштыру проектының техник-икътисадый нигезләмәсе яки кирәкле исәп-хисаплар;

г) объектларны планлаштырылган җир кишәрлегендә урнаштыру ихтыяҗын раслаучы башка документлар.»;

11 нче пунктта «а – в» пунктчаларында» сүзләрен «а – б» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

16 нчы пунктның беренче абзацында «күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастрын» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\393.docx